**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**О внесении изменения в Указ Президента Республики Татарстан «Об определении параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения»**

В целях совершенствования правового регулирования в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов **постановляю**:

1. Внести изменение в Указ Президента Республики Татарстан от 12 апреля 2013 года № УП-303 «Об определении параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения», изложив параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения, в новой редакции согласно приложению.

2. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
14 декабря 2013 года
№ УП-1216

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «14 » декабря 2013 года

№ УП- 1216

# Параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения

## I. Любительская и спортивная охота в отношении охотничьих ресурсов (за исключением видов и подвидов млекопитающих и птиц, занесенных в Красную книгу Российской Федерации и Красную книгу Республики Татарстан)

1.1. Охота на лосей (все половозрастные группы) осуществляется с 18 октября по 15 января.

1.2. Охота на пернатую дичь в весенний период охоты осуществляется с третьей субботы апреля в течение 10 календарных дней.

## II. Промысловая охота, охота в целях осуществления научно-исследовательской деятельности, образовательной деятельности, охота в целях регулирования численности охотничьих ресурсов, охота в целях акклиматизации, переселения и гибридизации охотничьих ресурсов, охота в целях содержания и разведения охотничьих ресурсов в полувольных условиях или искусственно созданной среде обитания

Промысловая охота, охота в целях осуществления научно-исследовательской деятельности, образовательной деятельности, охота в целях регулирования численности охотничьих ресурсов, охота в целях акклиматизации, переселения и гибридизации охотничьих ресурсов, охота в целях содержания и разведения охотничьих ресурсов в полувольных условиях или искусственно созданной среде обитания осуществляется в соответствии с действующим законодательством.

## III. Ограничения охоты

Запрещается любительская и спортивная охота на 2013 – 2014 годы во всех государственных природных охотничьих заказниках, за исключением государственного природного охотничьего заказника «Камско-Икский».

____________

**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклanыла торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә хокукый яктан җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указына, Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 ел, 14 декабрь
№ ПУ-1216

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның «__14__» _декабрендәге_
ПУ-_1216_ номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрлары**

I. Аучылык ресурсларына карата үзешчән һәм спорт авы
(Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән имезүчеләр һәм кош-корт төрләреннән һәм ярдәмче төрләреннән тыш)

1.1. Пошиларны (барлык җенес-яшь төркемнәре) 18 октябрьдән 15 гыйнварга кадәр ауларга мөмкин.

1.2. Язгы чорда киек кошларга ау апрельнең өченче шимбәсеннән алып 10 календарь көн дәвамында тормышка ашырыла.

II. Кәсеп авы, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыру максатларындагы ау, аучылык ресурслары санын җайга салу максатларындагы ау, аучылык ресурсларын акклиматизацияләү, күчерү һәм гибридлаштыру максатларындагы ау, аучылык ресурсларын ярым ирекле шартларда яисә ясалма булдырылган яшәү мохитендә тоту һәм үрчетү максатларындагы ау

Кәсеп авы, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыру максатларындагы ау, аучылык ресурслары санын җайга салу максатларындагы ау, аучылык ресурсларын акклиматизацияләү, күчерү һәм гибридлаштыру максатларындагы ау, аучылык ресурсларын ярым ирекле шартларда яисә ясалма булдырылган яшәү мохитендә тоту һәм үрчетү максатларындагы ау гамәлдәге законнар нигезендә тормышка ашырыла.

III. Ауны чикләүләр

«Кама-Ык» дәүләт табигать аучылык заказнигыннан тыш, барлык дәүләт табигать аучылык заказникларында 2013 – 2014 елларга үзешчән һәм спорт авы тыела.

_________